| УПРАВЛЕНИЕ ПО НАДЗОРУ ЗА ТЕХНИЧЕСКИМ СОСТОЯНИЕМ САМОХОДНЫХ МАШИН И ДРУГИХ ВИДОВ ТЕХНИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗЙӨРЕШЛЕ МАШИНАЛАР ҺӘМ БАШКА ТӨР ТЕХНИКАНЫҢ ТЕХНИК ТОРЫШЫНА КҮЗӘТЧЕЛЕК ИДАРӘСЕ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

24.09.2024 Казан ш. № 01-05/240-пр

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең 20.05.2024 ел, № 01-05/143-пр боерыгы белән расланган Техник торышына региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыра торган органнарда теркәлгән үзйөрешле машиналарга һәм башка төр техникага техник тикшерү уздыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүне камилләштерү һәм элек чыгарылган норматив актларны федераль законнар таләпләренә туры китерү максатларында,

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең «Техник торышына региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыра торган органнарда теркәлгән үзйөрешле машиналарга һәм башка төр техникага техник тикшерү уздыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 20.05.2024 ел, № 01-05/143-пр боерыгы белән расланган Техник торышына региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыра торган органнарда теркәлгән үзйөрешле машиналарга һәм башка төр техникага техник тикшерү уздыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Күзәтчелек һәм автоматлаштырылган нигездә исәпкә алу бүлегенә әлеге боерыкны һәм кертелгән үзгәрешләре белән Административ регламент текстын «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталының Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм

башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең рәсми сайтында «Документлар» бүлегенең «Административ регламентлар» бүлекчәсендә урнаштырырга.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Җитәкче А.Ш.Борһанов

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең 24.09.2024 № 01-05/240-пр боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең «Техник торышына региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыра торган органнарда теркәлгән үзйөрешле машиналарга һәм башка төр техникага техник тикшерү уздыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 20.05.2024 ел, № 01-05/143-пр боерыгы белән расланган Техник торышына региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыра торган органнарда теркәлгән үзйөрешле машиналарга һәм башка төр техникага техник тикшерү уздыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2 бүлектә:

2.3.1 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе «Гостехнадзор Эксперт» автоматлаштырылган мәгълүмат системасында теркәлә, аннары тракторларны, үзйөрешле машиналарны һәм аларга тагылмаларны исәпкә алу һәм теркәү буенча федераль дәүләт мәгълүмат системасына ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын кулланып җибәрелә.»;

2.3.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен кәгазьдә һәм (яисә) формасы техник карау узу турында таныклык яисә кәгазьдә техник карау акты рәвешенә туры килә торган электрон документ рәвешендә алырга хокуклы.

Техник карау узу турында таныклыкны һәм техник карау актын электрон документ рәвешендә рәсмиләштерү Бердәм порталның һәм (яисә) Республика порталының, шулай ук «Гостехнадзор Эксперт» автоматлаштырылган мәгълүмат системасының техник мөмкинлеге булганда гамәлгә ашырыла.»;

2.4.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү әлеге Регламентның 2.8.1 пунктында күрсәтелгән нигезләр барлыкка килгән очракта туктатыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору срогы, дәүләт хезмәтен туктатып тору өчен нигезләрне билгеләгән көннән соң, 30 календарь көннән артып китә алмый.

2.6.1 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) машиналарга техник тикшерү уздыру турында дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза):

- Идарәгә, Идарә бүлегенә, күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать иткәндә, кәгазь чыганактагы документ формасында (әлеге Регламентка 1 нче кушымта (юридик затлар һәм физик затлар өчен));

- Бердәм портал, Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта, Регламентның 2.6.4 пункты таләпләре нигезендә имзаланган электрон формада (гаризаның электрон формасына тиешле белешмәләрне кертү юлы белән тутырыла);»;

2.6.2 пунктта:

өченче абзацта «(мөрәҗәгать итүче инициативасы белән тапшырылырга мөмкин)» сүзләрен өстәргә;

бишенче һәм алтынчы пунктчаларны көчен югалткан дип танырга;

2.6.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Регламентның 2.6.5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.»;

2.8.1 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү мөрәҗәгать итүче шушы Регламентның 2.6.2 пунктының 1, 2 һәм 4 пунктчаларында күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта, шулай ук аларның дөреслегенә шик барлыкка килгәндә туктатыла.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору (яңарту) турында карар, туктатып тору (яңарту) сәбәпләрен күрсәтеп, әлеге Регламентка 2 нче (7 нче кушымта) кушымта нигезендә рәсмиләштерелә һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору (яңарту) турында карар кабул ителгән көнне мөрәҗәгать итүчегә аның тарафыннан алуның сайланган ысулы нигезендә тапшырыла:

язмача формада мөрәҗәгать итүчегә шәхсән яисә почта аша;

электрон документ формасында электрон почта адресы буенча һәм (яки) Бердәм порталда, Республика порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына.»;

2.8.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге:

1) мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документлар (белешмәләр) ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алынган белешмәләргә каршы килә;

2) машинага техник тикшерү уздыру турында документ биргән өчен дәүләт пошлинасын түләү турында мәгълүмат юк.»;

3 бүлектә:

3.1 пунктның бишенче абзацында «өчен нигезләр» сүзләреннән алда «туктатып тору яисә» сүзләрен өстәргә;

3.5, 3.5.1, 3.5.2 пунктларда «баш тарту өчен» сүзләрен «туктатып тору яисә баш тарту өчен» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле $3.5^1$ пунктын өстәргә:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү туктатып торылган вакыт эчендә техник карау уздыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору сәбәпләрен бетерүне раслый торган документлар алынса, Идарәнең баш дәүләт инженер-инспекторы шушы Регламентка 7 нче кушымта нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүне яңарту турында карар проектын рәсмиләштерә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура дәүләт хезмәтен күрсәтүне яңарту турында карар кабул ителгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе булып дәүләт хезмәтен күрсәтүне яңарту турында карар тора.»;

3.5.2 пунктта «баш тарту турында» сүзләрен «туктатып тору яисә баш тарту турында» сүзләренә алмаштырырга;

Әлеге Регламентка 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Техник торышына региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыра торган органнарда теркәлгән үзйөрешле машиналар һәм башка төр техникага техник тикшерү уздыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Кая ______________________________________________
(үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышы һәм алардан файдалану өлкәсендә региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле булган Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимият органының тулы атамасы (алга таба – дәүләт техник күзәтчелек органы))

Кемнән ______________________________________________
(физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) яисә юридик затның тулы исеме йә юридик затның аерымланган бүлекчәсе атамасы)

| Тел. | ОГРНИП/ОГРН | ИНН |
| --- | --- | --- |

Адресы: ______________________________________________
(физик затның яшәгән урыны адресы)

шәхес таныклаучы документ ______________________________
(исеме, сериясе, номеры, кем тарафыннан бирелгән)

______________________________________________

Индекс ____________, юридик зат урнашкан урын чикләрендә юридик зат адресы яисә аның аерымланган бүлекчәсенең урнашкан урыны адресы ______________________

______________________________________________

______________________________________________

**Үзйөрешле машиналарга һәм техниканың башка төрләренә техник тикшерү уздыру турында**
**ГАРИЗА**

Әлеге белдерүгә кушымта нигезендә үзйөрешле машиналарга һәм техниканың башка төрләренә (алга таба - машиналарга) техник карау (ТК) үткәрүегезне сорыйм.

Теркәлә торган документлар: ______________________________

______________________________________________

______________________________________________

Дәүләт пошлинасын түләү турында
квитанция № ______________ «____» ______________ 20____ ел.
Сумма ________________________________________________ сум.
Җыем түләү турында
квитанция № ______________ «____» ______________ 20____ ел.
Сумма ________________________________________________ сум.

| Машиналарга ТК уздыру турында мәгълүмат |
| --- |
| Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тутырыла ________________________ |
| Үзйөрешле машиналарга ТК түбәндәге адрес буенча уздыруыгызны үтенәм: ________________________ |
| ________________________ |
| ________________________ |
| Карау өчен «____» ______________ 20____ ел. |
| Тикшерү вакыты ______________ |

Үзйөрешле машиналарга ТК уздыру эше ышанып тапшырыла:

________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), вазыйфасы, шәхесне раслаучы документ исеме, сериясе, номеры, кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән, ышанычнамә турында белешмәләр)

________________________________________________

________________________________________________

______________ (элемтә өчен телефон) ______________ (имза) ______________ (оешма җитәкчесенең фамилиясе, инициаллары) ______________ (дата)

Мөһер урыны (булган очракта)

Әлеге гариза нигезендә Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгына һәм эшкәртүне гамәлгә ашыруга, шул исәптән автоматлаштырылган режимда, ризалык бирүемне раслыйм

________________________________________________
(дәүләт техник күзәтчелек органының тулы исеме)

минем персональ белешмәләремне (эшкә сәләтле булмаган затның – персональ белешмәләр субъектының персональ белешмәләрен (мөрәҗәгать итүче законлы вәкил булып торган очракта) персональ белешмәләрне җыюны, системага салуны, туплауны, саклауны, төгәенләштерүне (яңартуны, үзгәртүне), файдалануны, шәхси булуыннан туктатуны, таратуны (шул исәптән өченче затларга тапшыруны), файдалана алмаслык итүне, юкка чыгаруны да кертеп).

Әлеге килешү мәгълүматларны эшкәртүнең чик срокларын билгеләми. Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыкны кире алу тәртибе миңа билгеле.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртү турында мәгълүмат бирү өчен субъектның элемтә өчен мәгълүматы:

________________________________________________
(почта адресы, телефон)

________________________________________________
(электрон почта адресы)

«____» ______________ 20____ ел. Имза ______________

| Гаризаны кабул итү турында тамга |
| --- |

|  |
|---|
| Дата: «____» ________________ 20___ ел.<br>Дәүләт техник күзәтчелек органы<br>дәүләт инженер-<br>инспекторы ______________________________ Имза: ______________<br>(фамилия, инициаллар)<br>Мөһер урыны |

Машиналарга ТК дәүләт инженеры – дәүләт техник күзәтчелек органы инспекторы уздырды
______________________________________________________________________
(фамилия, инициаллар)

ИМЗА ______________________

Мөһер урыны

Үзйөрешле машиналарга һәм техниканың башка төрләренә техник тикшерү уздыру турында гаризага кушымта

| т/с | Үзйөрешле машина һәм техниканың башка төрләре атамасы һәм маркасы | Дәүләт теркәү билгесе (булган очракта) | Чыгарылу елы | Завод номеры, тәңгәллек номеры (VIN яки PIN) | Двигателенең номеры | Үзйөрешле машина һәм техниканың башка төрләре паспорты (сериясе, номеры) яисә үзйөрешле машина һәм техниканың башка төрләренең электрон паспорты (уникаль номеры) (дәүләт теркәвенә кадәр техник карау уздырылган очракта ) | Карауны уздыру адресы | Техник карау уздыру турында талон (серия, номер)». |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | | | | | |
| 2. | | | | | | | | |
| 3. | | | | | | | | |
| 4. | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |

Әлеге Регламентка 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Техник торышына региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыра торган органнарда теркәлгән

үзйөрешле машиналар һәм башка төр техникага техник тикшерү уздыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Кемгә

*(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) – гражданнар һәм шәхси эшкуарлар өчен)*
*(оешманың тулы исеме – юридик затлар өчен)*

Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору турында
20___ елның «__» _______
КАРАР

Техник торышына региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыра торган органнарда теркәлгән үзйөрешле машиналар һәм башка төр техникага техник тикшерү уздыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентының 2.8.1 пункты нигезендә ___________________ (*хезмәт күрсәтү өчен гариза датасы*) тапшырылган №_________ (*хезмәт күрсәтүгә гариза номеры*) документларны карап тикшерү нәтиҗәсендә техник торышына региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыра торган органнарда теркәлгән үзйөрешле машиналарга һәм башка төр техникага техник тикшерү уздыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында карар кабул ителде, чөнки (*баш тарту нигезе*):
______________________________________________________________________
______________________________________________________.

Хезмәтләр күрсәтүне туктатып тору өчен мотивлаштырылган нигезләү:_____________________________________________________________
______________________________________________________________________.

Өстәмә рәвештә хәбәр итәбез: ______________________________ (*хезмәтләр күрсәтүне туктатып тору сәбәпләрен бетерү өчен кирәкле мәгълүмат күрсәтелә*).

| Электрон имза турында белешмәләр |
|---|

*(карар кабул итүне гамәлгә ашыручы органның вәкаләтле заты вазыйфасы)* *(имза)* *(Ф.И.А. (булган очракта))*»

Регламентка түбәндәге редакциядә 7 нче кушымта өстәргә:

«Техник торышына региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә

ашыра торган органнарда теркәлгән үзйөрешле машиналар һәм башка төр техникага техник тикшерү уздыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 7 нче кушымта

Кемгә

*(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) – гражданнар һәм шәхси эшкуарлар өчен)*
*(оешманың тулы исеме – юридик затлар өчен)*

Дәүләт хезмәтен күрсәтүне яңарту турында
20___ елның «__» _______
КАРАР

Хезмәт күрсәтүне туктатып тору турында карар кабул итүгә сәбәпче булган нигезләрне бетерүне раслаучы документларны карау нәтиҗәләре буенча:
______________________________*(документ(лар)ның исем (исемнәре) һәм реквизитлары күрсәтелә)*
_________________________________________________________
______________________________________________________________________________
Техник торышына региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыра торган органнарда теркәлгән үзйөрешле машиналарга һәм башка төр техникага техник тикшерү уздыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрергә.

| Электрон имза турында белешмәләр |
|---|

*(карар кабул итүне гамәлгә ашыручы органның вәкаләтле заты вазыйфасы)* *(имза)* *(Ф.И.А. (булган очракта))*»